**«Велосипедчы җыры»**

1. Таудан төшәм, үргә менәм,
   Кояшка таба барам.
   Ерактагы урман белән
   Якынаядыр арам.

*Кушымта:*

Тер-тер – тәгәрмәчләр,<br>
Тәгәри дә тәгәри.<br>
Велосипедта җилдерәм<br>
Әллә-ли дә әллә-ли! *(2 тапкыр)*

2. Аякларга күз иярми –
   Педальне әйләндерәм.
   Шундый матур, күңелле көн,
   Иркен әйләнә-тирәм.

*Кушымта:*

Тер-тер – тәгәрмәчләр,<br>
Җилфер-җилфер җилләре.<br>
Йөрик әле, күрик әле<br>
Туган-үскән җир ямен! *(4 тапкыр)*